**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «27» декабреннән №51-398

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 24 ноябрендәге 15-110 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон ның 44 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 12 октябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 24 ноябрендәге 15-110 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 20 апрелендәге 33-260 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 39-319 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2. пунктының 11 пунктчасына «,шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 4 статьясының 4.1 өлешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 7 абзацында «район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны үстерүне, тәэмин итүне булдыра,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктның сигезенче абзацына «, шулай ук рекреацион максатлар өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен» сүзләрен өстәргә;

5 пунктны түбәндәге эчтәлекле 14 абзац белән тулыландырырга:

«әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерә.";

8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 6 абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә, су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми

файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, билгеләү, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгели;».

1.3. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 8.1. өлешенең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфасыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана (устав нигезендә башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы белән килештереп билгеләү гамәлгә ашырыла);».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов